| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 сентябрь 2024ел № 5723

Башкарма комитетның 2024 елның 18 апрелендәге 2472 номерлы Карары белән расланган даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2024 елның 18 апрелендәге 2472 номерлы Карары белән расланган даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә, 58 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«58. Субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шул исәптән Башкарма комитет һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланганда, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта, субсидия алучыга карата субсидияне шәһәр бюджетына кире кайтару рәвешендә җаваплылык чарасы күрелә.

Субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе бозылу һәм (яки) әлеге Тәртипнең 44 пункты белән каралган нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешмәү ачыкланган очракта, Башкарма комитет өч эш көне эчендә субсидия алучыга кимчелек турында белдерү кәгазе һәм субсидияне шәһәр бюджетына кире кайтару турында таләп җибәрә.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов